ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РУССКО-АЗЕЛЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
РУС ӘҖИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның 30 гыйнвары Рус Әҗиле ав. № 3

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Рус Әҗиле авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон,«Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Хөкүмәте «2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы карары нигезендә Рус Әҗиле авыл җирлеге Башкарма комитеты
**КАРАР ИТӘ:**

1. 2026 елның 1 февраленнән Зеленодольск муниципаль районының Рус Әҗиле авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 9 678,63 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Рус Әҗиле авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2025 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы Карарын 2026 елның 01 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. 8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталының Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1йорт (җирлек администрациясе бинасы), Карәшәм авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Рус Әҗиле авыл җирлеге башлыгы урынбасары И.Ш.Хаялиев

Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге башкарма комитеты 2026 елның 30 гыйнварындагы № 3 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегендә 2026 елның 1 нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (бер сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 5 274,38 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратта ташу | 1 502,49 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 2 901,76 |
| **Барлыгы** | **9 678,63** |

Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге башкарма комитеты 2026 елның 30 гыйнварындагы № 3 карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегендә 2026 елның 1 нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (бер сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 5 274,38 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратта ташу | 1 502,49 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 2 901,76 |
| **Барлыгы** | **9 678,63** |